КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 май г.Казань № 352

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен, шулай ук урта һөнәри белем бирү программаларын, шул исәптән сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге (кураторлыгы) өчен айлык акчалата түләү билгеләү турында» 2020 ел, 10 август, 671 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен, шулай ук урта һөнәри белем бирү программаларын, шул исәптән сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге (кураторлыгы) өчен айлык акчалата түләү билгеләү турында» 2020 ел, 10 август, 671 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 04 октябрь, 946 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф

җитәкчелеге өчен,  шулай ук урта һөнәри белем бирү программаларын, шул исәптән сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә  сыйныф җитәкчелеге (кураторлыгы) өчен бер сыйныф җитәкчесенә, сыйныф җитәкчесенә (кураторга) түбәндәге күләмнәрдә айлык акчалата түләү (алга таба - түләү) билгеләргә:

халкының саны 100 мең һәм аннан да күбрәк булган торак пунктларда аена 5 000 сум;

халкының саны 100 мең кешедән ким булган торак пунктларда аена 10 000 сум».

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                                    А.В.Песошин